ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ КАЙБИЦКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ КАЙБЫЧ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

28.07.2022 Олы Кайбыч ав. № 334/1

Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Олы Кайбыч авыл җирлег Генераль планы проекты буенча гавами тыңлаулар билгеләү турында

Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 28 статьясына, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 28 статьясына таянып, Татарстан Республикасы «Кайбыч муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Уставы, Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Советының 2008 елның 23 маендагы 138 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районында гавами тыңлауларны оештыру һәм уздыру тәртибе турында нигезләмә нигезендә Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Башкарма комитеты КАРАР ИТӘ:

1. Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Олы Кайбыч авыл җирлеге Генераль планы проекты буенча гавами тыңлаулар билгеләргә.

2. Гавами тыңлаулар үткәрү инициаторы булып Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Башкарма комитеты тора.

2. Түбәндәгеләрне билгеләргә:

- үткәрү вакыты: 2022 елның 29 августында 10 сәгать 00 минутта;

- үткәрү урыны: Кайбыч районы, Олы Кайбыч авылы, Кояшлы бульвар урамы, 7 нче йорт адресы буенча урнашкан Олы Кайбыч авыл җирлегенең административ бинасы;

- 2022 елның 29 августына кадәр тикшерелә торган мәсьәлә буенча тәкъдимнәр һәм искәрмәләр кертелергә мөмкин булган адреслар:

Кайбыч районы, Олы Кайбыч авылы, Кояшлы бульвар ур., 7 йорт - Кайбыч муниципаль районы Башкарма комитетының инфраструктура үсеше бүлеге;

Кайбыч районы, Олы Кайбыч авылы, Кояшлы бульвар урамы, 7 йорт - Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының Олы Кайбыч авыл җирлеге Башкарма комитеты.

Кайбыч муниципаль районының Олы Кайбыч авыл җирлеге Башкарма комитетына Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының Олы

Кайбыч авыл җирлеге Генераль планы проекты буенча гамәлдәге законнар нигезендә һәм әлеге карар белән билгеләнгән срокларда гавами тыңлаулар әзерләргә һәм уздырырга тәкъдим итәргә.

5. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат – телекоммуникация челтәрендә http:// kaybici.tatarstan.ru веб-адресы буенча Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга һәм http://pravo.tatarstan.ru веб-адресы буенча «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында» бастырып чыгарырга.

6. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Башкарма комитет Җитәкчесенең төзелеш һәм ТКХ буенча урынбасары Сәлахов Б.Р.ка йөкләргә.

Җитәкче А.Н. Макаров